ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2023 – 2024 елларда Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкның торышы турында Татарстан Республикасы Конституция советы доклады хакында

Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе И.И. Гыйлаҗев тарафыннан тәкъдим ителгән 2023 – 2024 елларда Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкның торышы турында Татарстан Республикасы Конституция советы докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2023 – 2024 елларда Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкның торышы турында Татарстан Республикасы Конституция советы докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Конституция советына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкны ныгыту максатларында Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән актив хезмәттәшлек алып бару эшен дәвам итәргә.

2.2. Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкның үсешен фәнни-методик тәэмин итүне, шул исәптән фәнни-гамәли чаралар үткәрү юлы белән, гамәлгә ашырырга.

2.3. Татарстан Республикасы халкын хокукый агартуга, аның хокукый әхлагын булдыруга һәм үстерүгә, шул исәптән гражданнарны кабул итү, тематик чаралар үткәрү һәм Татарстан Республикасында конституциячел законлылык мәсьәләләре буенча публикацияләр бастырып чыгару юлы белән, ярдәм күрсәтергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына Татарстан Республикасы Конституция советы белән берлектә Татарстан Республикасы Конституция советының кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга, Татарстан Республикасында

конституциячел законлылыкны ныгытуга юнәлтелгән эшчәнлеген законнар белән җайга салуны камилләштерү эшен дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына тиешле эшчәнлек тармакларына һәм өлкәләренә караган мәсьәләләр буенча гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Конституция советы тәкъдимнәрен һәрьяклап карауны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм башка оешмаларга 2023 – 2024 елларда Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкның торышы турында Татарстан Республикасы Конституция советы докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 28 марты
№ 226-VII ДС